Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

2020 елның 25 сентябре 4№

**Муниципаль берәмлек башлыкларының, муниципаль берәмлек башлыклары урынбасарларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлек башлыклары урынбасарларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 658 номерлы карары нигезендә, Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 1 октябреннән Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның 12 апрелендәге «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау турында»147 номерлы (Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы 166 номерлы, 2018 елның 27 июлендәге 170 номерлы, 2018 елның 27 сентябрендәге 186 номерлы карарларында кертелгән үзгәрешләр белән) карары нигезендә Әлки муниципаль районы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, Әлки муниципаль районы муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык акчалата хезмәт хакы күләмен 1,03 тапкырга арттырырга.

2. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның

12 апрелендәге «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау турында»147 номерлы (Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы 166 номерлы, 2018 елның 27 июлендәге 170 номерлы, 2018 елның 27 сентябрендәге 186 номерлы карарларында кертелгән үзгәрешләр белән) карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районындагы муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләп чыгару өчен әлеге Карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладлары күләмен 1,03 тапкырга индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ йөкләргә.

Совет рәисе
Әлки муниципаль районы Башлыгы: А. Ф. Никошин